РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ

БОЕРЫК

«10» октября 2022г. с. Тюлячи № 228

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 270 номерлы «2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләрнең прейскурантын раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен нәтиҗәле файдалану максатларында,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 270 номерлы «2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләрнең прейскурантын раслау турында» боерыгына (12.11.2020 № 214, 14.09.2022 № 185 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскурантын түбәндәге редакциядә кушымта нигезендә.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 28.10.2019 ел № 270 боерыгына кушымта

2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскуранты

1. Күмәк шуу:

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Категория | Вакыты | Бәясе |
|---|---|---|---|
| Тимераяклар алмыйча күмәк шуу (шәхси тимераяклар белән) | 5 яшькә кадәр балалар | 1 сәгать | Түләүсез |
| | | | |
| | 14 яшькә кадәр ятим балалар | 1 сәгать | Түләүсез |
| | Инвалидлыгы булган балалар | 1 сәгать | Түләүсез |
| | 5 яшьтән 14 яшькә кадәр балалар | 1 сәгать | 50 сум |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Пенсионерлар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Инвалидлыгы булган өлкәннәр | 1 сәгать | 50 сум |
| | Күпбалалы гаиләләр әгъзалары | 1 сәгать | 50 сум |
| | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән балалар | 1 сәгать | түләүсез |
| | Халыкның башка категорияләре | 1 сәгать | 100 сум |
| Тимераякларны вакытлыча куллануга алып тору | 14 яшькә кадәр балалар | 1 сәгать | 100 сум |
| | 14 яшькә кадәр ятим балалар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Инвалидлыгы булган балалар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Күпбалалы гаиләләр әгъзалары | 1 сәгать | 50 сум |
| | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән балалар | 1 сәгать | түләүсез |
| | Пенсионерлар | 1 сәгать | 100 сум |
| | Халыкның башка категорияләре | 1 сәгать | 150 сум (абонемент сатып алганда 10 баруга 1200 сум) |

Искәрмә: ташламалар таныклыклар күрсәткәндә бирелә.

2. Боз шугалагын арендалау:

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Бәясе |
|---|---|
| Боз шугалагын арендалау (1 сәгать) | 3000 сум |

3. Башка хезмәтләр:

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Категория | Бәясе |
|---|---|---|
| Тимераякларны кайрау (1 пар) | Халыкның барлык категорияләре өчен | 150 сум |
| Хоккей киемендә иректә уен | 16+ категориясе өчен | Бер кешегә 150 сум Уенчылар саны 10 кешедән артык булганда хезмәт күрсәтү «Боз шугалагын арендалау» хезмәте буенча һәм әлеге прейскурант нигезендә башкарыла |

Искәрмә: санап чыгу буенча түләү мөмкинлеге. Ташламалар гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча чакыруны раслаучы таныклык, хәрби комиссариатның белешмәсен күрсәткәндә бирелә.».

2. Әлеге боерык гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин